КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 20 июнь г.Казань № 399

Гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен
оештыру турында

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрмәүче балалар өчен мәктәпкәчә белем алуны тәэмин итү, мәктәпкәчә белемнең вариатив формаларын үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен оештыру турында үрнәк нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен оештырганда әлеге карар белән расланган Гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен оештыру турында үрнәк нигезләмә нигезендә эш итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Сынау проектындагы мәктәпкәчә белем учреждениеләрендә гаилә балалар бакчаларын оештыру турында" 2010 ел, 1 март, 99 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\399.docx